КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 октябрь г.Казань № 925

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 28 июнь, 476 нчы карары белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы территориясендә «Туризмны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «туристлык сәяхәтләре саны» күрсәткеченә ирешү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы территориясендә «Туризмны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «туристлык сәяхәтләре саны» күрсәткеченә ирешү белән бәйле аларның чыгымнарының бер өлешен финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 28 июнь, 476 нчы карары белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы территориясендә «Туризмны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «туристлык сәяхәтләре саны» күрсәткеченә ирешү белән бәйле аларның чыгымнарының бер өлешен финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән сайлап алу юнәлеше буенча чикләнмәгән санда заявкалар бирергә һәм әлеге Тәртипнең 12 һәм 13 пунктларында күрсәтелгән сайлап алу юнәлешләренең һәркайсы буенча иң күбе бер заявка бирергә хокуклы.»;

25 пунктның унсигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучының гамәлгә ашырыла торган проект белән бәйле җир кишәрлегенә хокукларын (аренда, милек) раслый торган хокук билгеләүче документларның күчермәләре яки, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитутлар, гавами сервитут билгеләмичә, дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә объектлар урнаштыруга рөхсәтнамә күчермәсе (әлеге Тәртипнең 11 яки 13 пунктларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча заявкалар бирелгән очракта);»;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаның 3 бүлеге таблицасындагы 12 юлның 1 графасына «яки җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитутлар, гавами сервитут билгеләмичә, дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә объектлар урнаштыруга рөхсәтнамә» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтадагы проект тасвирнамәсенең 7 пунктына «яки җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитутлар, гавами сервитут билгеләмичә, дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә объектлар урнаштыруга рөхсәтнамә» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин